**Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы**
**Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәр Советы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 90-17 «26» июль 2022 ел

Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү тәртибен җайга сала торган аерым норматив хокукый актларның үз көчләрен югалтуын тану турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Татартан Республикасының 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы муниципаль хезмәт турында Кодексы, Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында» Указы нигезендә,

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәр Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай район Советы карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

- 2014 елның 29 декабрендәге 151-44 номерлы «Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү, шулай ук «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмә турында»;

- 2015 елның 19 мартындагы 161-45 номерлы Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында, шулай ук Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмә хакында".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб адрес буенча бастырырга: http://pravo.tatarstan.ru. һәм Азнакай муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга: http//aznakayevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Азнакай район Советының Законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис М. З. Шәйдуллин